**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2024елның 20 мае** **41-РС номер**

# КАРАР

## «2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2023 елның 25 декабрендәге 152-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лаеш муниципаль районы Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) турында» 2023елның 25 декабрендәге 152-РС номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертергә (кушымта):

- 2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) 2 нче кушымтаны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның җирле үзидарә органнары белән законлылык, хокук тәртибе һәм үзара хезмәттәшлек буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Лаеш муниципаль районы*
*Советының 2024 елның 20 мая*
*41-РС номерлы карарына*
*кушымта*

**2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы)**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2024 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Лаеш муниципаль районының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү турында нигезләмә нигезендә (алга таба - фаразлау планы) эшләнде.

Муниципаль милекне (алга таба муниципаль милек) хосусыйлаштыру бурычлары булып:

- муниципаль милек структурасын оптимальләштерү;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы бюджетының керем өлешен тулыландыру;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә эшкуарлыкны үстерү өчен уңайлы мохит булдыру.

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә төп юнәлешләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең муниципаль мөлкәттән бертигез файдалану һәм ачыклыгы принципларына нигезләнгән үтә күренмәле һәм нәтиҗәле приватизация процедураларын куллану;
- Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә файдаланылмаган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру.

**II. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт**

2024 елга хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге әлеге Программага 1 нче кушымтада китерелгән.

2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) 1нче кушымта

**2024 елга хосусыйлаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан биналар, төзелешләр, корылмалар һәм җир кишәрлекләре исемлеге**

| № т/б | Муниципаль мөлкәт исеме | Урыны | Бинаның, төзелешнең, корылманың мәйданы (кв.м) | Җир участогы мәйданы (кв.м) | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Бина (кадастр номеры 16:24:080101:1242) һәм җир участогы 16:24:080101: 123 | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге поселок, Мәктәп урамы, 4 нче йорт | 180,6 | 720 | 2024 ел дәвамында |
| 2 | Административ бина (кадастр номеры 16:24:050601:10106) һәм кадастр номеры 16: 24: 110103:168 булган җир участогы | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Хәерби авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт | 638,2 | 2282 | 2024 ел дәвамында |
| 3 | Кадастр номеры 16:24:050601:1576 булган административ бина һәм кадастр номеры 16:24:240304:14 булган җир участогы | Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мешенская урамы, 1 нче йорт | 570,9 | 1313 | 2024 ел дәвамында |
| 4 | Кибет (кадастр номеры 16:24:050601:9329) һәм кадастр номеры 16:24:020101: 48 булган җир участогы | ТР, Лаеш районы, Имәнкискә авылы | 206,8 | 263 | 2024 ел дәвамында |
| 5 | ФАП бинасы (кадастр номеры 16:24:000000:2049) һәм кадастр номеры 16:24:180201:42 булган җир участогы | ТР, Лаеш районы, Курманак авылы, Үзәк урам, 27Б йорт | 54,7 | 433 | 2024 ел дәвамында |
| 6 | "Заслон" киртәсе секциясе | ТР, Казан шәһәре,»Казан ипподромы " ҖЧҖ | 162 шт. |  | 2024 ел дәвамында |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Сантехник контейнерлар | ТР, Лаеш районы, Никольский авылы | 7 шт. | | 2024 ел дәвамында |
| 8 | Балалар бакчасы бинасы (кадастр номеры 16:24:160101:810) һәм кадастр номеры 16:24:160101:175 булган җир участогы | ТР, Лаеш районы, Олы Кабан авылы, Овражная урамы, 15 йорт | 421,7 | | 2024 ел дәвамында |
| 9 | Торак булмаган бина мәдәни-спорт комплексы (кадастр номеры 16:24:050601:3299) һәм кадастр номеры 16: 24: 210101:374 булган җир участогы | Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Габишев авыл җирлеге, Габишев авылы, Совет урамы, 5 йорт | 3864,4 | 10345 | 2024 ел дәвамында |
| 10 | Бакча йорты (кадастр номеры 16:24:257001:518) һәм кадастр номеры 16:24:257001:26 булган җир участогы | ТР, Лаеш муниципаль районы, Орел авыл җирлеге, коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте «Механик", 26 йорт | 67,8 | 615,0 | 2024 ел дәвамында |
| 11 | Торак булмаган бина «Орловский полигон», кадастр номеры: 16: 24: 140601: 44, җир участогы, кадастр номеры:16:24:140601: 1076 | ТР, Лаеш муниципаль районы, Орел авылы, Олимпия урамы, 2А йорт | 82,0 | 100000,0 | 2024 ел дәвамында |